| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 ноября 2020 года п.г.т. Алексеевское № 6

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Сабакайка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Уставының 22.1 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 24 ноябренә 10 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Сабакайка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге тәрбияләүдә 3 тән артык баласы булган гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләрне төзү һәм төзекләндерү;
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү;

- суүткәргеч һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.
ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**